БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_10_» ___01____ 2020 ел № _7__

**«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Региональ программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган, «2017, 2018, 2019 елларда Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планын раслау турында»гы Балтач район башкарма комитетының 2017 елның 11 февралендәге 86 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2016 елның 30 декабрендәге 280 номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге 300 номерлы, 2018 елның 5 декабрендәге 365 номерлы, 2019 елның 5 мартындагы 124 номерлы үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Торак кодексын, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Региональ программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган, «2017, 2018, 2019 елларда Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планын раслау турында»гы Балтач район башкарма комитетының 2017 елның 11 февралендәге 86 номерлы карарына (2017 елның 29 декабрендәге 300 номерлы карар керткән үзгәрешләр белән) 2017, 2018, 2019 елларда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планын яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итеп үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район
башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
20_____ елның ____________
______ номерлы карары белән
расланган

2017, 2018, 2019 елларда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планы

I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан, 2017, 2018, 2019 елларда Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның әлеге кыска вакытлы планы (алга таба - тиешле урында Кыска вакытлы план, Муниципаль программа) «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон), «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) нигезендә Муниципаль программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау вакытларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең төрләрен төгәлләштерү, капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында эшләнде.

II. Кыска вакытлы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
Балтач муниципаль районында торак фондын саклау, торгызу һәм аның сыйфатын күтәрү;
гражданнар өчен имин һәм уңайлы яшәү шартлары булдыру;
күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм.
Кыска вакытлы планның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;
Кыска вакытлы планны башкаручыларны сайлап алуның ачык һәм гавами процедураларын эшләү һәм үтәү;
чыдам материаллар һәм ресурслар саклый торган технологияләр кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләрне һәм комплекслылыкны файдалану.
Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру вакыты -2017, 2018, 2019 еллар.
Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 14,376 мең кв.метр булган 9 күпфатирлы йортта 363 гражданның имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге Кыска вакытлы планны үтәү буенча планлаштырылган күрсәткечләр Кыска вакытлы планга 1 нче кушымтада күрсәтелгән.

## III. Кыска вакытлы планны үтәүдә катнашучы шәһәр һәм авыл җирлекләре исемлеге

Балтач муниципаль районының кыска вакытлы планны үтәүдә катнашучы шәһәр һәм авыл җирлекләре исемлеге, мондый җирлекләрнең территориясендә түбәндәгеләр булуын исәпкә алып формалаштырылган:

а) Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлгән;

б) Балтач муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы (ел саен) муниципаль планнары дәүләт торак күзәтчелеге органнары белән расланды һәм килештерелде.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыруда Норма авыл җирлеге һәм Балтач шәһәр җирлеге катнаша.

## IV. 2017 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләме.

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән: | метр | 85,3 |
| су белән тәэмин итү | метр оз. | 2,5 |
| ташландык суларны чыгару | метр оз. | 82,8 |
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | метр оз. | 96 |
| Түбәләрне ремонтлау | кв. метр | 999 |
| Фасадны ремонтлау | кв. метр | 743,88 |
| Подъездларны ремонтлау | кв. метр | 96 |

2018 елда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләме.

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме |
|---|---|---|
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | кв. метр | 196,7 |
| Исәпләү җайланмаларын, идарә итү узелларын урнаштыру | данә | 2 |
| Фасадны ремонтлау | кв. метр | 2279,83 |
| Подъездларны ремонтлау | кв. метр | 196,71 |

2019 елда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләме.

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме |
|---|---|---|
| Ташландык суларны чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | метр | 149,7 |
| Фасадны ремонтлау | кв. метр | 850,2 |
| Түбәләрне ремонтлау | кв. метр | 666 |
| Подъездларны ремонтлау | кв. метр | 62 |
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | кв. метр | 119 |

Күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү күләмнәре Кыска вакытлы планга 2 нче кушымтада китерелгән.

## V. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска вакытлы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар һәм күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләренең акчалары тора.

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме тәшкил итәчәк

**2017 ел:** 3655497,79 сум, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы- 1393145,68 сум;

җирле бюджетлар акчасы– 1128000,00 сум;

күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләренең акчасы - 1134352,11 сум;

**- 2018 ел:** 6037124,54 сум, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 212602,79 сум;

җирле бюджетлар акчасы - 1128000,00 сум;

күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләренең акчасы - 4696521,75 сум;

**- 2019 ел:** 3983705,44 сум, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1344630,51 сум;

җирле бюджетлар акчасы - 1128000,00 сум;

күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләренең акчасы - 1511074,93 сум;

Капиталь ремонт үткәрүнең бәясен күрсәтеп, күпфатирлы йортлар исемлеге кыска вакытлы планга 3 нче кушымтада китерелгән.

## VI. Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру механизмы

Әлеге кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты, идарә оешмалары, урын милекчеләре, подрядчы оешмалар (алга таба - Кыска вакытлы планны үтәүчеләр) тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты:

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – Министрлык) Региональ программаны гамәлгә ашыру буенча кыска вакытлы (ел саен) муниципаль планнарны формалаштыра һәм җибәрә;

Министрлыкка муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлешен раслаучы норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм башка документлар тапшыра;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнаша;

җирле бюджет акчаларын Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм торак законнары нигезендә әлеге кыска вакытлы планда билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт эшләрен финанслашуга күчерә;

Региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча техник заказчы функцияләрен гамәлгә ашыра;

башкарылган эшләрнең актларын, капиталь ремонт эшләрен кабул итү актларын, күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау өчен расланган чыгымнар сметасында каралмаган акчадан файдалану очракларыннан тыш, шулай ук чыгымнар арткан очракта, килештерә;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау эшләрен уздыруга бүлеп бирелә торган акчалардан максатчан файдалануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

Министрлык билгеләгән тәртиптә тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру максатларында мәгълүматлар базасын (шул исәптән күпфатирлы йортларда торак һәм торак булмаган урыннар мәйданнары буенча мәгълүматлар) барлыкка китерә һәм актуаль хәлдә тота;

Министрлыкка һәм Кыска вакытлы планның башка башкаручыларына Фондка хисап формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне тапшыра.

Идарәче оешмалар:

капиталь ремонт өчен түләүләр буенча ай саен милекчеләргә түләүләрне исәпләүне башкаралар, урын милекчеләреннән капиталь ремонт өчен түләүләр рәвешендә бирелә торган акчаны җыялар, капиталь ремонт фонды Региональ операторы счетында төзелгән очракта, капиталь ремонтка милекчеләрнең түләүләрен Региональ оператор счетына күчерәләр, Торак фонды объектларына капиталь ремонт ясау һәм мониторинг ясау буенча дәүләт программасы үтәлешен формалаштыру һәм мониторинглау Интеграцияләнгән мәгълүмат-аналитика системасына һәр милекче буенча исәпләүләр һәм түләү турында түбәндәге һәркем файдалана алырлык web-адрес буенча мәгълүматны урнаштыралар: https://bars-monjf.tatarj-u/monjf/;

капиталь ремонтка түләүләр буенча урын милекчеләренең бурычлары барлыкка килүгә юл куймау буенча чаралар күрәләр;

тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә карата җитешсезлек (дефект) ведомостьларын, башкарылган эшләрнең актларын килештерәләр;

региональ оператор белән түләү документларын формалаштыру өчен һәм капиталь ремонтка түләүләр буенча милекчеләрнең ай саен исәпләүләрен һәм түләүләрен региональ оператор счетына күчерүне тәэмин итү өчен шартнамәләр (килешүләр) төзиләр;

дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алу белән проект документларын әзерләүне тәэмин итәләр;

Министрлык тарафыннан расланган тәртип нигезендә сайлап алуны оештыручы булып торалар;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнашалар;

урын милекчеләренә капиталь ремонт башлану вакыты, хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең кирәкле исемлеге һәм күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында тәкъдимнәр һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр кертәләр;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча милекчеләр җыелышларын оештыралар:

капиталь ремонт объектларына керүне рөхсәт итүне гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тотуда, шулай ук, капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү актларын һәм аларны файдалануга тапшыру актларын имзалау хокукы белән, капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортларны файдалануга алуда катнашалар;

күпфатирлы йортка капиталь ремонт буенча җитешсезлек (дефект) ведомостьларын, проект-смета һәм башкарма документларны күпфатирлы йортны һәм аңа керә торган инженерлык системаларын аварияcез эксплуатацияләүнең билгеләнгән гарантия вакытыннан да ким булмаган вакыт дәвамында саклыйлар.

Урын милекчеләре:

капиталь ремонт эшләре күләменә карата җитешсезлек (дефект) ведомостьларын, тикшерү актларын килештерәләр;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тотуда, шулай ук, капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү актларын һәм аларны файдалануга тапшыру актларын имзалау хокукы белән, капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортларны файдалануга алуда катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Кыска сроклы план һәм подряд килешүе белән билгеләнгән вакыт эчендә эшләрне башкаруны тәэмин итәләр;

КС-2, КС-3 формасы буенча башкарылган эшләрнең актларын формалаштыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы;

объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

Техник заказчы функцияләрен башкаручы оешма:

проект документларын, шул исәптән сметаны әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыра;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыра;

башкарылган эшләрне кабул итүдә катнаша, башкарылган эшләрнең актларын килештерә;

объектны файдалануга кабул итүдә катнаша, объектны файдалануга кабул итүнең актын килештерә;

күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы;

проект оешмасыннан проект-смета документларын кабул итә;

күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча күрсәтелгән хезмәтләрне (яки) башкарылган эшләрне кабул итү актына кул кую датасыннан соң 10 көн эчендә әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүче затка күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү турындагы документларның күчермәләрен (шул исәптән, проектның, смета документларының, хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) капиталь ремонт эшләрен башкару турында килешүләрнең күчермәләре) һәм капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документлар, финанс документларыннан тыш, тапшыра;

техник заказчының законнарда каралган башка функцияләрен гамәлгә ашыра,

Район массакүләм мәгълүмат чаралары - «Хезмәт» («Труд») һәм "Кайтаваз" ТРК массакүләм мәгълүмат чараларында кыска вакытлы планның чараларын гамәлгә ашыру барышын даими яктыртып торалар.

Кыска вакытлы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «Торак фонды мониторингы» бердәм мәгълүмат продуктында гамәлгә ашырыла.

## VII. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен башкару өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе

Подрядчы оешмалар Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган тәртип нигезендә Региональ оператор, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары, муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан сайлап алына.

2017-2019 елларда Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан
күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча
Региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планына
1 нче кушымта

**2017 – 2019 елларда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планын үтәүнең планлаштырылган күрсәткечләре**

| т/б № | Муниципаль берәмлек исеме | Күпфатирлы йортларның гомуми мәйданы, кв. метр | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Региональ программа расланган көнгә күпфатирлы йортларда яшәүчеләр саны | Күп фатирлы йортлар саны, берәмлек | | | | | Капиталь ремонтның бәясе, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | барлыгы | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | барлыгы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| 2017 ел | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Балтач муниципаль районы | 3 462,41 | 120 | | | | 3 | 3 | | | | 3 655 497,79 | 3 655 497,79 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2018 ел | | | | | | | | | | | | | |
| 2 | Балтач муниципаль районы | 9 135,76 | 199 | | | | 4 | 4 | | | | 6 037 124,54 | 6 037 124,54 |
| 2019 ел | | | | | | | | | | | | | |
| 3 | Балтач муниципаль районы | 1 779,16 | 44 | | | | 2 | 2 | | | | 3 983 705,44 | 3 983 705,44 |

2017-2019 елларда Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы территориясендә
урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми
мөлкәткә капиталь ремонт буенча
Региональ программаны гамәлгә ашыруның
кыска вакытлы планына
2 нче кушымта

2017-2019 елларда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планына кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар
реестры

| т/б № | т/б № | Күпфатирлы йортның адресы | Капиталь ремонт бәясе - барлыгы | Шул исәптән: | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | төзелеш-монтаж эшләренең бәясе | файдалану, лифт шахталарын ремонтлау өчен яраксыз дип табылган лифт җиһазларын алыштыру | җылылык энергиясен кулланунның идарә итү һәм җайга салу узелларын урнаштыру | күпфатирлы йортка энергетика тикшерүләре үткәрү | күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү буенча эшләр үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү | 2017 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета бәясен дөрес | 2018 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета бәясен дөрес | 2019 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета бәясен дөрес | 2020 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документларын эшләү һәм капиталь ремонтның смета бәясен дөрес | төзелеш контролен гамәлгә ашыру |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | итеп билгеләүне тикшерү үткәрү | итеп билгеләүне тикшерү үткәрү | итеп билгеләүне тикшерү үткәрү | итеп билгеләүне тикшерү үткәрү | |
| | | | сум | сум | сум | берәмлек | сум | берәмлек | сум | берәмлек | сум | сум | сум | сум | сум | сум |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| 2017 ел | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Балтач муниципаль районы | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | 1. | штп. Балтач, Тынычлык урамы, 20 нче йорт | 1 709 967,57 | 1 631 045,60 | 0,00 | 0 | 0,00 | 0 | 0,00 | 1 | 5 994,00 | 53 753,87 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 19 174,10 |
| 2 | 2. | штп. Балтач, Төзүчеләр урамы, 5 нче йорт | 600 721,61 | 567 802,61 | 0,00 | 0 | 0,00 | 0 | 0,00 | 1 | 13 599,00 | 14 490,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 4 830,00 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | 3. | Кариле авылы, Заһидуллин урамы, 2 нче йорт | 1 344 808,61 | 1 273 966,24 | 0,00 | 0 | 0,00 | 0 | 0,00 | 1 | 6 554,00 | 48 216,14 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 16 072,23 |
| Район буенча барлыгы | | | 3 655 497,79 | 3 472 814,45 | 0,00 | 0 | 0,00 | 0 | 0,00 | 3 | 26 147,00 | 116 460,01 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 40 076,33 |
| 2018 ел | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Балтач муниципаль районы | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | 1. | штп. Балтач, З. Космодемьянская урамы, 1в номерлы йорт | 2 390 033,88 | 2 257 258,81 | 0,00 | 0 | 0,00 | 1 | 3 845,00 | 1 | 28 900,00 | 0,00 | 75 022,55 | 0,00 | 0,00 | 25 007,52 |
| 2 | 2. | штп. Балтач, Ленин урамы, 17 нче йорт | 133 570,32 | 90 770,32 | 0,00 | 0 | 0,00 | 0 | 0,00 | 1 | 38 800,00 | 0,00 | 3 000,00 | 0,00 | 0,00 | 1 000,00 |
| 3 | 3. | штп. Балтач, Ленин урамы, 19 нчы йорт | 126 970,32 | 90 770,32 | 0,00 | 0 | 0,00 | 0 | 0,00 | 1 | 32 200,00 | 0,00 | 3 000,00 | 0,00 | 0,00 | 1 000,00 |
| 4 | 4. | штп. Балтач, | 3 386 | 3 203 | 0,00 | 0 | 0,0 | 1 | 4 989 | 1 | 35 700,0 | 0,00 | 106 680,00 | 0,00 | 0,00 | 35 560,0 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Нариман урамы, 43 нче йорт | 550,02 | 621,02 | | | 0 | | ,00 | | 0 | | | | | 0 |
| Район буенча барлыгы | | | 6 037 124,54 | 5 642 420,47 | 0,00 | 0 | 0,00 | 2 | 8 834,00 | 4 | 135 600,00 | 0,00 | 187 702,55 | 0,00 | 0,00 | 62 567,52 |
| 2019 ел | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Балтач муниципаль районы | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | 1. | штп. Балтач, Ленин урамы, 129 нчы йорт | 2 284 675,89 | 2 218 255,89 | 0,00 | 0 | 0,00 | 0 | 0,00 | 1 | 8 900,00 | 0,00 | 0,00 | 43 140,00 | 0,00 | 14 380,00 |
| 2 | 2. | штп. Балтач, Ленин урамы, 131 нче йорт | 1 699 029,55 | 1 634 778,55 | 0,00 | 0 | 0,00 | 0 | 0,00 | 1 | 6 900,00 | 0,00 | 0,00 | 43 013,70 | 0,00 | 14 337,30 |
| Район буенча барлыгы | | | 3 983 705,44 | 3 853 034,44 | 0,00 | 0 | 0,00 | 0 | 0,00 | 2 | 15 800,00 | 0,00 | 0,00 | 86 153,70 | 0,00 | 28 717,30 |

2017-2019 елларда Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы территориясендә
урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми
мөлкәткә капиталь ремонт буенча
Региональ программаны гамәлгә ашыруның
кыска вакытлы планына
3 нче кушымта

**2017 - 2019 елларда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планына кертелгән күпфатирлы йортлар исемлеге**

| т/б № | КФЙ адресы* | Ел | | Стена материалы | Катлар саны | Подъездлар саны | КФЙның гомуми мәйданы - барлыгы, кв. метр | КФЙ урыннарның мәйданы, кв. метр | | Программа расланган көнгә КФЙта теркәлгән кешеләр саны, кеше | КФЙка капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы | Ремонт төре | Капиталь ремонтның бәясе, сум | | | | КФЙның гомуми мәйданының 1 кв.метрында капиталь ремонтның чагыштырма бәясе (удельная стоим | КФЙның гомуми мәйданының 1 кв. метрына капиталь ремонтның чик бәясе | Эшләрне тәмамлауның планлы датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | файдалануга тапшыру | соңгы капиталь ремонтны тәмамлау | | | | | барлыгы | шул исәптән гражданнар милкендәге торак урыннарда | | | | барлыгы | шул исәптән | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән | җирле бюджет хисабына | ТМШ***, башка кооперативлар яки КФЙтагы урыннарның милекчеләре акчалары | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | | хисабына | ость) | | |
| | | | | | | | | | | | махсус счет/региональ оператор счеты | | | | | | сум/кв. метр | сум/кв. метр | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| Балтач муниципаль районы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | штп. Балтач, Тынычлык урамы, 20 нче йорт | 1969 | 1969 | кирпеч | 2 | 2 | 1 126,50 | 876,50 | 247,91 | 25 | региональ оператор счеты | төзелеш контролен гамәлгә ашыру, ПСД, күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү эшләрен башкару | 1 709 967,57 | 663 162,59 | 543 828,96 | 502 976,02 | 1 517,95 | 14 000,00 | 30.08.2017 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | һәм техник паспортлар әзерләү, салкын су белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, ташландык суларны чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, түбәләрне ремонтлау, фасадны ремонтла | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | у | | | | | | | |
| 2 | штп. Балтач, Төзүчеләр урамы, 5 нче йорт | 1976 | 2008 | кирпеч | 3 | 2 | 1 514,06 | 871,06 | 1 127,16 | 78 | региональ оператор счеты | төзелеш контролен гамәлгә ашыру, ПСД, күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү эшләрен үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү, түбәне ремонтлау | 600 721,61 | 249 756,08 | 200 679,60 | 150 285,93 | 396,76 | 14 000,00 | 30.08.2017 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Кариле авылы, Заһидуллин урамы, 2 нче йорт | 1989 | 1989 | кирпеч | 2 | 1 | 821,85 | 495,65 | 263,20 | 17 | региональ оператор счеты | төзелеш контролен гамәлгә ашыру, ПСД, күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү эшләрен үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү, ташландык суларны чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, фасадны ремонтлау, электр белән | 1 344 808,61 | 480 227,01 | 383 491,44 | 481 090,16 | 1 636,32 | 14 000,00 | 31.08.2017 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, салкын су белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, подъездларны ремонтлау, подъездларны ремонтлау. | | | | | | | |
| Район буенча бар | | | | | | | 3 462,41 | 2 243,21 | 1 638,27 | 120 | | | 3 655 497,79 | 1 393 145,68 | 1 128 000,00 | 1 134 352,11 | 1 055,77 | 14 000,00 | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| лыгы | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Балтач муниципаль районы | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | штп. Балтач, З. Космодемьянская урамы, 1в номерлы йорт | 1990 | 1990 | кирпеч | 2 | 3 | 2 393,03 | 1 211,11 | 853,26 | 28 | региональ оператор счеты | төзелеш контролен гамәлгә ашыру, ПСД, фасадны ремонтлау, күп фатирлы йортларга техник инвентаризация үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү, күпфатирлы йортка энергетика тикшерүләре үткәрү, подъездларны ремонтлау, электр белән | 2 390 033,88 | 83 797,33 | 44 4 599,98 | 1 861 636,57 | 998,75 | 14 000,00 | 30.12.2018 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау. | | | | | | | |
| 2 | штп. Балтач, Ленин урамы, 17 нче йорт | 1972 | 2008 | кирпеч | 3 | 3 | 2 026,19 | 866,90 | 1 307,09 | 57 | региональ оператор счеты | җылылык исәпләү җайланмаларын урнаштыру, ПСД, төзелеш контролен гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү эшләрен үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү | 133 570,32 | 4 543,53 | 24 106,42 | 104 920,37 | 65,92 | 14 000,00 | 30.12.2018 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | штп. Балтач, Ленин урамы, 19 нчы йорт | 1975 | 2008 | жыелма-щит панельләр | 2 | 3 | 2 506,83 | 1 367,31 | 950,60 | 38 | региональ оператор счеты | күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү эшләрен үткәрү һәм техник паспортлар ясау, җылылыкны исәпкә алу җайланмаларын урнаштыру, ПСД, төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 126 970,32 | 4 319,03 | 22 915,32 | 99 735,97 | 50,65 | 14 000,00 | 30.12.2018 |
| 4 | штп. Балтач, Нариман урамы, 43 нче йорт | 1997 | 1997 | кирпеч | 2 | 3 | 2 209,71 | 839,23 | 1 211,11 | 76 | региональ оператор счеты | төзелеш контролен гамәлгә ашыру, ПСД, подъездларны ремонтлау, күпфатир | 3 386 550,02 | 119 942,90 | 636 378,28 | 2 630 228,84 | 1 532,58 | 14 000,00 | 30.12.2018 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | лы йортларны техник инвентаризациялəү эшлəрен үткəрү һəм техник паспортлар əзерлəү, күпфатирлы йортка энергетика тикшерүен үткəрү, фасадны ремонтлау, электр белəн тəэмин итүнең йорт эчендəге инженерлык системаларын ремонтлау. | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Район буенча барлыгы | | | | | | | 9 135,76 | 4 284,55 | 4 322,06 | 199 | | | 6 037 124,54 | 212 602,79 | 1 128 000,00 | 4 696 521,75 | 660,82 | 14 000,00 | 15.09.2018 |
| Балтач муниципаль районы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | штп. Балтач, Ленин урамы, 129 нчы йорт | 1965 | 1965 | кирпеч | 2 | 1 | 1 280,67 | 714,83 | 364,90 | 22 | региональ оператор счеты | ташландык суларны чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, фасадны ремонтла | 2 284 675,89 | 673 293,13 | 564 820,34 | 1 046 562,42 | 1 783,97 | 14 000,00 | 31.12.2019 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | у, түбәне ремонтлау, ПСД, төзелеш контролен гамәлгә ашыру, подъездларны ремонтлау, күпфатирлы йортларны техник инвентаризациялә ү эшләрен үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү | | | | | | | |
| 2 | штп. Балтач, Ленин урамы, 131 нче йорт | 1966 | 1966 | кирпеч | 2 | 1 | 498,49 | 263,20 | 289,90 | 22 | региональ оператор счеты | түбәне ремонтлау, фасадны ремонтлау, электр белән тәэмин итүнең йорт | 1 699 029,55 | 671 337,38 | 563 179,66 | 464 512,51 | 3 408,35 | 14 000,00 | 31.12.2019 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, ташландык суларны чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, төзелеш контролен гамәлгә ашыру, ПСД, подъездларны ремонтлау, күпфатирлы йортларны техник инвентаризацияләү | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | эшләрен үткәрү һәм техник паспортлар әзерләү | | | | | | | |
| Район буенча барлыгы | | | | | | | 1 779,16 | 978,03 | 654,80 | 44 | | | 3 983 705,44 | 1 344 630,51 | 1 128 000,00 | 1 749 008,49 | 2 596,16 | 14 000,00 | 31.12.2019 |